**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Нижнекамский городской**
**С О В Е Т**

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
факс (8555) тел.42-42-66

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Түбән Кама шәһәр**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр12
факс (8555) тел.42-42-66

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2016 елның 15 декабре № 36**

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында гавами тыңлаулар үткәрү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, шулай ук Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 21 статьясына, 16 бүлегенә таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы Карары проектын (1 нче кушымта) хупларга һәм халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү вакыты: 26 декабрь, 2016 ел, 16: 00 сәгатьтә, Төзүчеләр пр., 12 адресы буенча урнашкан Советлар йортының кече залында.

3. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм гражданнарның фикер алышуларда катнашуы тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты Түбән Кама шәһәр Советының оештыру бүлеге белән берлектә:

4.1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.e-nizhnekamsk.ru) урнаштырырга;

4.2. «Нижнекамская правда» һәм «Туган як» газеталарында Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында хәбәр бастырырга;

4.3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган (басма басмада - «Ленинская правда» газетасы 2006 елның 10 ноябрендәге 220-221 (8572-8573), ачык тыңлаулар үткәрүне, гражданнардан һәм вазыйфаи затлардан кергән тәкъдимнәрне һәм ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризаларны кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре мэры урынбасары Э. Р. Долотказинага йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2016 елның 15 декабрендәге 36
номерлы карарына
1 нче кушымта

**ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР**

**СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ**

№ “__“ _______ 20__ г.

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен игътибарга алып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. Түбән Кама шәһәре Мэрына (А.Р. Метшин) әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвен алу өчен җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының Регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
201 елның __ _______ __
номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы**
**Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. **«Шәһәрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә хокукы» турындагы 7 статьяның** 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пункт белән тулыландырырга:

13) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.

2. **«Шәһәр Башкарма комитеты вәкаләтләре» турындагы 51 статьяның** 7 пунктын түбәндәге эчтәлекле 7.17 пунктчасы белән тулыландырырга:

«7.17. «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина

Түбән Кама шәһәр Советының
2016 елның 15 декабрендәге
36 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА «ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА КАРАТА ГРАЖДАННАР ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы Карары проектына тәкъдимнәр Түбән Кама шәһәр Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12 (Советлар йорты бинасы), 202 нче кабинет, яисә Таб-лицалар рәвешендә язма рәвештә 42-42-66 факсы буенча, кушымта итеп бирелә торган үрнәк нигезендә, төзәтмәләр рәвешендә 42-42-66:

| № п/п | Пункт, пунктча | Проект текстының карары | Төзәтмәләр тексты | Проектның төзәтмәләр исәпкә алынган тексты | Төзәтмә авторы (Ф. И. О., адрес, телефон, эш яки уку урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12 йорт, шәхсән яки почта аша («Устав турында фикер алышу» яки «Гавами тыңлаулар» дигән тамга белән), шулай ук 42-42-66 факсы буенча.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Түбән Кама шәһәр Советының оештыру бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Түбән Кама шәһәр Советының Җирле үзидарә, депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә тапшырыла.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина